Муниципальное бюджетное образовательное учреждение” Черемшанская средняя общеобразовательная школа № 1 им. П. С. Курасанова»

Черемшанского муниципального района Республики Татарстан

«Согласовано»
Заместитель директора по ВР
МБОУ «Черемшанская СОШ №1
им.П.С.Курасанова»
_____________ /Ялышева А.Г./
« 29» августа 2023года

«Утверждено»
И.о директора МБОУ
«Черемшанская СОШ №1
им.П.С.Курасанова»
_____________ /Юрина НВ./
Приказ № 163 от 01.09 2023 г

# *Рабочая программа*
# *дополнительного образования*
# ***«Нәни театрчылар»***

*Возраст обучающихся – 8-9 лет*

*Учитель: Сулейманова Альфинур Вагизовна*

*Сроки реализации программы 2023-2024 уч. год.*

## Аңлатма язуы

Башлангыч сыйныфларда тәрбия эше эчтәлеген яңарта бару, инновацион технологияләрне куллану — тормыш таләбе. Бүген тәрбия эчтәлеге күпкырлы һәм ул үзенә түбәндәге өстенлекле юнәлешләрне берләштерә: балаларның физик һәм әхлакый сәламәтлеген саклау, ныгыту, интеллектуаль тәрбия бирү һәм үстерү, шәхестә культуралылык сыйфатлары һәм рухи кыйммәтләр булдыру; гражданлык тәрбиясе һәм патриотик тәрбия бирү, гаиләнең нәсел шәҗәрәсен өйрәнү, төрле җенестәге балаларның үзара дустанә мөнәсәбәте һ.б.

Баланы төрле яклап үстерү өчен, иң беренче чиратта, аның нәрсәгә сәләтле булуын ачыклау да җитә. Бу очракта күпләгән санда түгәрәкләргә йөртүдән тыш, аңа туры килә торган берсен сайлап алырга мөмкин. Мәктәптә бала яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашырга, әйберләрне танып белергә өйрәнә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур. Баланың бөтен тормышы уен. Уенда бала тирә- юнь турында, җәмгыятьнең законнары, кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый, ә бу дөньяда яшәргә, үзенең мөгамәләләрен төзергә өйрәнә. Ә бу баланың игътибарлы, яхшы хәтерле, дөрес, матур, әйбәт сөйләшә белүен таләп итә. Сәхнәләштерү уеннарында катнашып, балалар образлар, төсләр, авазлар аша тирә- юнь белән танышалар, ә сораулар балаларны уйларга, анализларга, йомгаклау ясарга мәҗбүр итә. Сәхнәләштерү эшчәнлеген алып барганда, һәр бала үзенең кичерешләрен, тойгыларын, теләкләрен, карашларын гадәти сөйләшкәндә генә түгел, ә чит тыңлаучылар алдында күрсәтә алырлык шартлар тудырырга һәм яшьтән үк өйрәтергә кирәк. Еш кына без киң белемле, сәнгатьле сөйләшә белүчеләрне оялчан икәнен, чит кешеләр алдында югалып калуларын күзәтәбез. Бу проблемалар булмасын өчен, театр куюю бик зур булышлык күрсәтә. Сәхнәләштерелгән уеннар балаларны шатландыралар. Спектакльләрдә катнашып, балалар тирә-юнь белән, төсләр, авазлар белән танышалар, ә уйланылып куелган сораулар балаларны анализларга, уйланырга, нәтиҗәләр ясарга өйрәтә. Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, сизелмичә баланың сүз байлыгы арта, бала чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек формалаша- яңа сүзләр белән баетыла.

**Программаның максаты:** Театр түгәрәгендәге шөгыльләр аша укучыларның сөйләм телләрен, иҗади активлыгын үстерү өчен шартлар булдыру. Аралашу культурасын һәм кеше арасыда үзеңне дөрес тота белү кагыйдәләрен фориалаштыру; сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру.

**Программаның төп бурычлары:**

- Акыл үсеше белән сөйләм теленең үсешен үстерү, персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләү, баланың сүз байлыгы арттыру, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләү;
- хәрәкәт күнекмәләрен формалаштыру;
- сәхнәләштерү эшчәнлегенә тотрыклы кызыксынуны үстерү ;
- мимика, ишарәләр, хәрәкәтләр, интонация тәэсирле чараларын кабатлау теләге тудыру.
- укучыларда эстетик, әхлак һәм хезмәт тәрбиясен тормышка ашыру;
- балаларның сәламәтлеген яхшырту;
- сәнгатькә кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.

**Эчтәлекне тәэмин итү принциплары:**

- Белем бирүдә фундаментальлек принцибы.

Үзләштергән белем һәм күнекмәләрнең балага рус әдәбиятын һәм башка милләтләр әдәбиятын үзләштергәндә дә ярдәм итә ала торган булу зарурлыгы.

- Аңлаешлылык (доступность) принцибы

.

Баланың нигез белемнәренә таянып, проблемалар, каршылыклар аша җиңеп чыгарлык, көче җитәрлек әсәрләрнең кулланышка куелуы.

- Мотивлылык принцибы.

Балаларның тормыш тәҗрибәләре, кызыксыну даирәләре белән тәңгәл килерлек, гыйбрәт яисә үрнәк алып тормыш тәҗрибәләрен баетырлык әсәрләрнең генә кулланышка куелуы. Танып-белү процессының психологик иркенлек шартларында оештырылу зарурлыгы.

- Күп мәдәни нигезлелек (поликультуралылык) принцибы.

Гомумкешелек кыйммәтләренә, сәнгать әсәре тудыра алган авторга (төрле милләт халкына да) ихтирам һәм кызыксыну хисләре уяну өчен; программа таләп иткән төп төшенчәләрнең татар һәм рус телләрендә үзләштерелүе өчен җирлек тудырылу.

- Системалы эшчәнлек ( системно- деятельностный подход) принцибы.

Программа таләп иткән эчтәлекне гадидән катлаулыга принцибы нигезендә бер бөтен буларак үзләштерелүе тәэмин ителү.

**Программаның билгеләнеше:**

“Нәни тетрчылар” түгәрәге программасы башлангыч сыйныф укучылар өчен тәкъдим ителә. Түгәрәк атнага 2 тапкыр үткәрелә.

**“Нәни театрчылар” түгәрәге программасының актуальлеге:** Кереп баручы стандартларының яңалыгы - белем һәм тәрбия алуда универсаль гамәлләрнең берсе коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы. Ягъни, баланың үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү. Бу таләп – түгәрәкнең актуальлеген раслаучы мөһим дәлил дә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

**Программаның структурасы:**

Программа 5 бүлектән тора һәм алар темаларга бүленгән.

1. Кереш. Театр уены
2. Без - яшь артистлар. Сөйләм теленең техникасы һәм культурасы
3. Театр культурасы нигезләре. Спектакль өстендә эш.
4. Җырлы-биюле, такмаклы уеннар өйрәнү. Төрле кичәләрдә уеннар белән катнашу.

Программа материалын өйрәнү 56 сәгатькә исәпләнә.

Сәхнәләштерү эшчәнлеге

- курчак театры карау һәм алар буенча әңгәмә оештыру;
- уен- драматизацияләр;
- сәнгатьле итеп сөйләү күнегүләре;
- этика буенча аерым күнегүләрне үз эченә ала.

Ә менә укытучы үзе сәнгатьле итеп сөйләү генә түгел, күрә, ишетә белергә, актерлык, режиссерлык осталыгына да әзер булырга тиеш. Тик ул үзенең актерлык осталыгы белән оялчан баланың уйнау теләген бетереп, караучыга әйләндерергә тиеш түгел. Балалар ялгышудан куркырга, гел караучы гына яки гел катнашучы гына булырга тиеш түгел.

Рольләргә бүлгәндә **төрле алымнар** кулланыла:

- баланың теләге буенча роль сайлау;
- төп рольләргә оялчан балаларны билгеләү;
- карточкалар буенча рольләргә бүлү;
- парлап уйнау.

Монда ике **проблема** килеп чыгарга мөмкин:

- һәр балага рольләр житмәсә нишләргә;
- тискәре рольләрне кем уйнар

Беренче проблеманы балаларны төркемнәргә бүлеп чишеп була. Ә икенчесен аңлатырга: әкияттә, сәхнәдә барысы да артистлар. Ә артист уңай рольне дә, тискәре рольне дә уйный белергә тиеш. Тискәре рольне уйнау күпкә катлаулырак та, һәр бала тискәре рольне дә, уңай рольне дә уйный белергә тиеш.

**«Нәни театрчылар» түгәрәге программасы эшчәнлегенең көтелгән нәтиҗәсе:**

Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшырды, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары артты, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туды. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсте.

- ✓ Балаларның милли культура, театр, артистлар дөньясы турында күп мәгълүмат белүе.
- ✓ Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыру, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арту, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туу. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсү.
- ✓ Сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшенү
- ✓ Үз туган ягыңның сәнгать кешеләре турында мәгълүмат алу.
- ✓ Практика белән теорияне кушып, тулыландыра алу мөмкинлеге булу.
- ✓ Гаилә белән мәктәп арасында җылы мөнәсәббәт тудыру.

## Тематик планлаштыру

| № | Тема | сәг. саны | Число |
|---|---|---|---|
| **I.** | **Кереш** | **1** | |
| 1. | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. | 1 | 06.09 |
| **II.** | **Без – яшь аристлар** | **12** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1-2 | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | 2 | 08.09;13.09 |
| 3 | Сәхнә серләренә өйрәнү. Видеоязмалар карау. | 1 | 15.09 |
| 4 | Оештыру эшләре. Түгәрәк әгъзаларының бурычлары. | 1 | 20.09 |
| 5-6 | Сәхнә теленең тормыштагы гади телдән аермасы. Хәрәкәтләр, мимика һәм гәүдә тотышы нәрсәләр турында сөйли? | 2 | 22.09; 27.09 |
| 7-8 | Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү | 2 | 29.09; 04.10 |
| 9 | Киенү-бизәнү осталыгы. Декорациянең роле. | 1 | 06.10 |
| 10 | Татар халык җырлары тыңлау һәм өйрәнү. | 1 | 11.10 |
| 11-12 | Татар халык әкиятләре. | 2 | 13.10; 18.10 |
| **II.** | **Сәхнә уеннары** | **13** | |
| 1-2 | “Теремкәй” әкиятенең эчтәлеге белән танышу. Рольләргә бүлеп уку. | 2 | 20.10; 25.10 |
| 3-4 | Сценарийны кабатлау. | 2 | 27.10; 01.11 |
| 5-6 | Сценарийны кабатлау. Хәрәкәтләрне өйрәнү. | 2 | 03.11; 08.11 |
| 7-8 | Сценарийны кабатлау. Музыкаль бизәлеш. Киемнәр әзерләү | 2 | 10.11; 15.11 |
| 9-10 | Сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек. | 2 | 17.11; 22.11 |
| 11 | Сәхнәгә кую. | 1 | 24.11 |
| 12-13 | Җырлы-биюле уеннар. | 2 | 29.11; 01.12 |
| **IV.** | **Яңа ел бәйрәменә театр-тамаша** | **8** | |
| 1-2 | Яңа ел бәйрәменә багышланган әкият-пьесаның эчтәлеге белән танышу. Рольләргә | 2 | 06.12; 08.12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бүлеп уку. | | |
| 3-4 | Сценарийны кабатлау. Хәрәкәтләр. Музыка | 2 | 13.12; 15.12 |
| 5 | Киемнәр әзерләү. | 1 | 20.12 |
| 6-7 | Җырлы-биюле һәм такмак әйтешле уеннар. | 2 | 22.12; 27.12 |
| 8 | Яңа ел бәйрәмендә чыгыш. | 1 | 29.12 |
| **V.** | **Спорт – сәламәтлек ул** | **5** | |
| 1 | Җитезлеккә уеннар өйрәнү. | 1 | 03.01 |
| 2-3 | Ярыш-эстафетага әзерләнү. Эмблема. Киемнәр. | 2 | 05.01; 10.01; |
| 4 | Ярыш-эстафеталар уздыру. | 1 | 12.01 |
| 5 | Спорт һәм бию ярышлары оештыру | 1 | 17.01 |
| **VI.** | **"Сәламәтлек театры" конкурсына** | **11** | |
| 1-2 | "Сәламәтлек театры" конкурсына сценарийс айлау, театр-тамашаның эчтәлеге белән танышу. Рольләргә бүлеп уку. | 2 | 19.01; 24.01 |
| 3 | Сәнгатьле уку буенча эш. | 1 | 26.01 |
| 4-5 | Театрны кабатлау. Хәрәкәтләр. Музыка. | 2 | 31.01; 02.02 |
| 6 | Киемнәр әзерләү. | 1 | 07.02 |
| 7-8 | Театр атналыгына әзерлек. | 2 | 09.02; 14.02 |
| 9 | Театр атналыгы конкурсында катнашу. | 1 | 16.02 |
| 10 | Балалар өчен җырлар өйрәнү. | 1 | 21.02 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11 | Татар халык бәйрәмнәре. | 1 | 28.02 |
| **VII.** | **Без табигать баласы** | **4** | |
| 1 | “Кошлар безнең дусларыбыз” музыкаль тамашаның эчтәлеге белән танышу. Рольләргә бүлеп уку. | 1 | 01.03 |
| 2 | Театрны кабатлау. Хәрәкәтләр. Музыка. | 1 | 06.03; |
| 3 | “Туган ягым – яшел бишек”. Экологик темага кичә. | 1 | 13.03 |
| 4 | Табигатькә экскурсия. Чишмәләрне чистарту. | 1 | 15.03; |
| **VIII** | **Йомгаклау** | **2** | |
| 1. | Эшләгән эшләргә анализ, нәтиҗә. | 1 | 20.03 |
| 2. | Күңелле ял. | 1 | 22.03 |

**Укучылар өчен әдәбият**


1. “Мәктәп сәхнәсе” сериясеннән китаплар.
2. Әдәплелек дәресләре (хрестоматия). Фәнни редакторы профессор Р.А.Низамов. Казан: Мәгариф, 2000.
4. Могҗизалы мәктәп сәхнәсе.Казан:Мәгариф,2003.
5. ”Мәктәп китапханәсе” сериясе томлыклар
6. ”Энҗе чәчтем” сериясеннән фольклор җыентыклары.
7. Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия.Төзүче- авторлары Л.И.Минһаҗева, И.И.Мияссарова, Казан-“Хәтер” нәшрияты, 2004
8. Татар халык әкиятләре.
9. Табышмаклар.
10. Мәкальләр.

**Файдаланылган әдәбият:**